ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

17.12.2020 Казан ш. № 553-13/тко-2020

Шәхси эшкуар Хикмәтуллин Рөстәм Тәлгат улы өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының 11.12.2019 № 11-32/тко карары белән билгеләнгән озак сроклы чик дәрәҗә тарифларга 2021 ел өчен үзгәреш кертү хакында

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә бәя кую турында» 2016 елның 30 маендагы 484 номерлы карары, Монополиягә каршы федераль хезмәтнең «Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салынучы тарифларны хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2016 елның 21 ноябрендәге 1638/16 номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә, 2021 елга каты коммуналь калдыкларны күмүгә озак сроклы тарифларны үзгәртү максатларында, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «2020-2022 елларга Шәхси эшкуар Хикмәтуллин Рөстәм Тәлгат улы өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә чик дәрәҗә тарифлар билгеләү турында» 11.12.2019 № 11-32/тко карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә);

2 нче кушымтаны яңа редакциядә бәян итәргә (кушымтада бирелә).

2. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис вазыйфаларын
вакытлыча башкаручы А.Л. Штром

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының
11.12.2019 № 11-32/тко
карарына 1 нче кушымта
(Татарстан Республикасының Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
17.12.2020 № 553-13/тко-2020
карары редакциясендә)

2020-2022 елларга шәхси эшкуар Хикмәтуллин Рөстәм Тәлгат улы өчен каты коммуналь калдыкларны күмүгә календарь буенча бүленгән чик дәрәҗә тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлекнең, каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салынучы эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Каты коммуналь калдыкларны күмүгә чик дәрәҗә тарифлар, сум/куб.метр | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2020 ел | | 2021 ел | | 2022 ел | |
| | | 1 гыйнвардан | 1 июльдән | 1 гыйнвардан | 1 июльдән | 1 гыйнвардан | 1 июльдән |
| | Кайбыч муниципаль районы | | | | | | |
| 1 | Шәхси эшкуар Хикмәтуллин Рөстәм Тәлгат улы* | 73,64 | 117,72 | 117,72 | 128,12 | 116,21 | 116,21 |

<*>Салым салуның гадиләштерелгән системасын куллана.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф чишелешләрен кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
11.12.2019 № 11-32/тко
карарына 2 нче кушымта
(Татарстан Республикасының Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
17.12.2020 № 553-13/тко-2020
карары редакциясендә)

Шәхси эшкуар Хикмәтуллин Рөстәм Тәлгат улы өчен 2020-2022 елларга каты коммуналь калдыкларны күмүгә чик дәрәҗә тарифларны озак сроклы җайга салу параметрлары

| № п/п | Каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендә җайга салынучы эшчәнлек төрләрен гамәлгә ашыручы оешманың аталышы | Ел | Операция чыгымнарының база дәрәҗәсе | Операция чыгымнарының нәтиҗәлелек индексы | Табышның норматив дәрәҗәсе | Энергияне саклау һәм энергетика нәтиҗәлелеге күрсәткечләре: электр энергиясенең чагыштырма сарыфы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | мең сум | % | % | кВт·с/куб.м |
| 1 | Кайбыч муниципаль районы | | | | | |
| 1.1 | Шәхси эшкуар Хикмәтуллин Рөстәм Тәлгат улы | 2020 | 3 360,47 | 1 | 0 | 0,05 |
| | | 2021 | 3 446,63 | 1 | 0 | 0,05 |
| | | 2022 | 3 535,00 | 1 | 0 | 0,05 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча
дәүләт комитетының тариф чишелешләрен
кабул итүне оештыру, контрольдә тоту һәм
теркәү бүлеге